**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **17 ноябрь 2023 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Әсәй авыл җирлеге составына керүче
Митрәй авылында 2024 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Митрәй авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2024 елда Әсәй авыл җирлеге Митрәй торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту, сатып алу, күчереп йөртү, вак таш тутыру, контракт буенча эшләр өчен түләү);
- Митрәй авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (дератизация, химик эшкәртү, гербицид белән химик эшкәртү, агачларны кисү, куакларны кисү, үләннәрне кисү, чүп-чар җыю, хуҗалык җиһазларын сатып алу, ГСМ, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Митрәй авылында су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итүче башка инженер корылмаларын (материал, җиһазлар сатып алу, торбаларны алмаштыру, янгын гидрантларын урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) проектлау һәм ремонтлау;

Митрәй авылында - урам яктырткычларын, электр товарларын, махсус җиһазларны сатып алу һәм аларга хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) һәм Әсәй авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әсәй авыл җирлеге Башлыгы Г.З. Дәминова.